Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Теләнче Тамак авылы

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«30» ноябрь, 2023 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Теләнче Тамак авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2024 елда яшәү урыны буенча Теләнче Тамак авыл җирлеге Теләнче Тамак авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Татарстан урамы, Теләнче-Тамак авылы буенча видеокүзәтү җайланмаларын сатып алу һәм урнаштыру
- Балалар бакчасы территориясендә балалар мәйданчыгын төзекләндерү (балалар уен элементларын сатып алу, урнаштыру)
- Күп фатирлы йортлар территориясен төзекләндерү
- Теләнче - Тамак торак пунктында милли Сабантуй бәйрәмен оештыру өчен бүләкләр алу;
- Теләнче-Тамак торак пунктында урамнарны яктыртуны ремонтлау өчен электр җиһазлары һәм комплектлау элементлары (яктырткычлар) сатып алу;
- Теләнче-Тамак авылы Татарстан урамы буенча гомуми файдаланудагы территорияне төзекләндерү

2. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның, Теләнче Тамак авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гаилә әгъзаларының үзара салым буенча взносларын түләүдән азат итәргә

3. Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Теләнче Тамак авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Теләнче Тамак авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Теләнче Тамак авыл җирлеге Башлыгы Р.Ш. Нәҗметдинов